Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

5 февраль 2021 ел № 6/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында «Татарстан Республикасы Законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары (03.06.2020 № 45/4, 12.11.2020 № 3/6 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**6 статьяның 22 пунктында** «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

**13 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчада** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

**20 статьяның 4 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр Формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;».

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә керә торган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнне үз көченә керә.

Глава Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан, Председатель Совета Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан: М.Р. Гафаров